СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*

ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**«26» октябрь 2015 ел** **№ 7.1**

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Утар-Аты авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Утар-Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 октябрендәге 87 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә:

а) 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"Әлеге статьяның 1 пунктындагы 14-15 пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә."

б) 6 статьяның 1 п. пунктында түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13. Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын гамәлгә ашыру.»

в) 33 статьяда:

- 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1. Җирлек советы компетенциясендә:»;

- 1 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;»

г) 69 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
«5. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»

д) 79 статьяга түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турындагы карар, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, җирле бюджетны үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турында квартал саен белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар рәсми басылып чыгарга тиеш.»

2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән “Утар-Аты авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны бастырып чыгарырга.

4. Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән алып 10 көн эчендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр чыганагы турында белешмәләр җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Хәкимҗанов

СОВЕТ УТАР-АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "УТАР-АТЫНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" * ОГРН 1121690090165 * ИНН 1609012621